| | | |
|---|---|---|
| УПРАВЛЕНИЕ<br>ПО ОХРАНЕ И<br>ИСПОЛЬЗОВАНИЮ<br>ОБЪЕКТОВ<br>ЖИВОТНОГО МИРА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ<br>ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ<br>ҺӘМ АЛАРДАН<br>ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ |

**Приказ** **Боерык**

25.03.2016 Казан № 45-од

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсенең 2015 елның 2 июленнән 84-од номерлы "Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсендә ихтыяжлар бәрелешен хәл итү буенча Комиссия турында"гы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

2008 елның 25 декабреннән 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршылык күрсәтү" турындагы Федераль канун, 2015 елның 22 декабреннән 650 нче номерлы "Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, дәүләт федераль хезмәте вазифаларын,алмаштыручы һәм башка затлар белән, вазифаи бурычларын үтәгәндә, ихтияжлар бәрелешенә китерә торган яки китерергә мөмкин булган, шәхси кызыксыну килеп чыгу турында хәбәр итү тәртибе һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында"гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы белән тәңгәл килеп **боерам:**

1. Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсенең 2015 елның 2 июленнән 84-од номерлы "Татарстан Республикасы-ның дәүләт гражданлык хезмәткәрләре-нең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсендә ихтыяжлар бәрелешен хәл итү буенча Комиссия турында"гы боерыгы ( алга таба – Боерык) белән расланган,

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенең дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау ,һәм ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча комиссия турында Кагыйдәнамәгә (алга таба – Кагыйдәнамә, Идарә) киләсе үзгәрешләр кертергә:

Боерыкның 1 нче пунктында Кагыйдәнамә исемендә, Кагыйдәнамәнең 1нче пунктында һәм Кагыйдәнамәнең 2 нче пунктында "Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе һәм ихтыяҗлар бәрелеше хәл итү" сүзләрен " Татарстан Республикасының һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсендә ихтыяҗлар бәрелеше хәл итү" сүзләренә алмаштырырга;

3 нче пунктның "а" кече пунктында " гражданлык хезмәткәрҗләре белән" сүзләреннән соң " Идарә" сүзен " Идарәдә Татарстан Республикасы" сүзлрено алмаштырырга;

6 нчы пунктны киләсе эчтәлекле кызыл юл белән тулыландырырга:

" Комиссиянең шәхси катнашмасы Идарә боерыгы белән раслана.";

15 нче пунктның "б" кече пунктын киләсе эчтәлекле кызыл юл белән тулыландырырга:

"вазифаи бурычларын үтәгәндә, ихтияҗлар бәрелешенә китерү яки китерергә мөмкин булу турында дәүләт хезмәткәренә белдерү;" ;

17 нче пункттан дүртенче җөмләне алып ташларга;

19 нчы пункттан икенче җөмләне алып ташларга;

19 нчы пунктны киләсе эчтәлекле кызыл юллар белән тулыландырырга:

"Бу Кагыйдәнамәнең 15 нче пункты "б" кече пунктының бишенче кызыл юлында күрсәтелгән белдерү, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны булдырмау буенча җаваплы зат белән карала, һәм каралган белдерүнең нәтиҗәләре буенча, аның белән мотивлаштырылган йомгак әзерләнә.

Бу Кагыйдәнамәнең 15 нче пункты "б" кече пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча,яки Бу Кагыйдәнамәнең 15 нче пункты "б" кече пунктының бишенче кызыл юлында һәм "д" кече пунктында күрсәтелгән белдерүнамәне карау нәтиҗәләре буенча, мотивлаштырылган йомгак әзерләгән вакытта, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны булдырмау буенча җаваплы зат, мөрәҗәгать иткән яки белдерүнамә биргән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә, аннан язмача аңлатма алырга хокуклы, ә Идарә башлыгы яки аның урынбасары, махсус вәкаләт бирелеп, билгеләнгән тәртиптә дәүләт әгъзаларына, җирле үзидарә әгъзаларына һәм башка оешмаларга сораулар җибәрергә хокуклы.

Мөрәҗәгать яки белдерүнамә, ә шулай ук йомгак һәм башка материаллар, мөрәҗәгать яки белдерүнамә бирелгәннән соң, җиде эш көнендә комиссия рәисенә тапшырылалар.

Мөрәҗәгать яки белдерүнамә сорату юлы белән юнәлткән очракта, ә шулай ук йомгак һәм башка материаллар, мөрәҗәгать яки белдерүнамә бирелгәннән соң, 45 эш көнендә комиссия рәисенә тапшырылалар. Күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артмаска тиеш.";

20 нче пунктның "а" кече пунктын түбәндәгечә сөйләп бирергә:



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

«а) 10 көн эчендә комиссия утырышының вакытын билгели. Шул ук вакытта Комиссия утырышы, күрсәтелгән мәгълүмат тапшырылганнан соң, Кагыйдәнәмәнең 21 һәм 22 пунктлары белән каралган очраклардан кала, 20 көннән дә соң булырга тиеш түгел;";

21 нче пунктта " өченче кызыл юлда күрсәтелгән гариза" сүзләрен "өченче һәм дүртенче кызыл юлларда күрсәтелгән гаризалар" сүзләренә алмаштырырга;

23 нче пунктны киләсе мөхәррияттә сөләп бирергә:

"23. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, аңа карата комиссия белән хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм ихтыяжлар бәрелешен хәл итү соравы карала торган, дәүләт хезмәткәре яки Идарәдә дәүләт хезмәте вазифасын алмаштырган гражданинның катнашуында алып барыла.

Комиссия утырышында шәхси катнашырга ниятләү турында, дәүләт хезмәткәре яки гражданин, Кагыйдәнамәнең 15 пунктының "б" кече пункты белән тәңгәл килеп бирелә торган, мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерүнамәдә күрсәтә.";

киләсе эчтәлекле 23.1. пункт белән тулыландырырга:

"23.1. Комиссия утырышы, дәүләт хезмәткәре яки гражданин үзе булмаган чакта, түбәндәге очракларда алып барылырга мөмкин:

а) Кагыйдәнамәнең 15 пунктының "б" кече пункты белән тәңгәл килеп бирелә торган, мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерүнамәдә, Комиссия утырышында шәхси катнашырга ниятләү турында күрсәтмә булмаса;

б) әгәр дә Комиссия утырышында шәхси катнашырга ниятләгән дәүләт хезмәткәре яки гражданин, тиешле рәвештә комиссия утырышының вакыты һә урыны турында белдерү алып, комиссия утырышына килмәгән очракта.";

киләсе эчтәлекле 26.1. пункт белән тулыландырырга:

"26.1. Бу Кагыйдәнамәнең 15 пунктының "б" кече пунктында күрсәтелгән сорауны карау нәтиҗәләре буенча, комиссия киләсе карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре белән вазифаи бурычларын үтәү барышында, ихтияжлар бәрелеше булмавын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре белән вазифаи бурычларын үтәү барышында, шәхси кызыксыну ихтыяжлар бәрелешенә алып килүне яки алып килергә мөмкин булуны танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) Идарә башлыгына ихтыяжлар бәрелешен көйләү буенча яки аны булдырмау буенча чаралар кабул итәргә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре ихтыяжлар бәрелешен көйләү таләпләрен тотмауны танырга. Бу очракта Комиссия Идарә башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.";

32 нче пунктны түбәндәгечә сөйләп бирергә:

"32. Бу Кагыйдәнамәнең 15 пунктының "а","б", "г" һәм "д" кече пунктларында күрсәтелгән сорауларны карау нәтиҗәләре буенча, аңа нигезләмә булган очракта, Комиссия бу Кагыйдәнамәнең 26-31 һәм 33 пунтларында каралган карарлардан кала, башка карар кабул итәргә мөмкин. Андый карарны кабул итү нигезләре һәм сәбәпләре Комиссия утырышының беркетмәсендә чагылырга тиеш.";

40 нчы пунктта "3 көн эчендә" сүзләрен "7 көн эчендә" сүзләре белән алмаштырырга.

Документ создан в электронной форме. № 683 от 26.04.2016. Исполнитель: Филиппова О.А.
Страница 20 из 22. Страница создана: 25.04.2016 14:09
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

3. Боерыкның үтәлүе артыннан тикшерүне Идарә башлыгы урынбасары Ю.Б.Матвеевка тапшырам.

Идарә башлыгы Ф.С.Батков